| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2021 Девәтернә авылы № 10-1

Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Девәтернә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына чираттагы утырыш көн тәртибенә Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Девәтернә авыл җирлеге органнарының вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү турындагы мәсьәләне карауны кертергә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетына Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органы белән тиешле килешү төзергә һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга

һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф.М. Йосыпов